КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 14 ноябрь г.Казань № 1206

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясе чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына финанс ярдәме күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган оешмасына субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 29 август, 624 нче карары үз көчен югалткан дип санау хакында» 2015 ел, 11 июнь, 427 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясе чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясе чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында

рече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына финанс ярдәме күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган оешмасына субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 29 август, 624 нче карары үз көчен югалткан дип санау хакында» 2015 ел, 11 июнь, 427 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 17 май, 321 нче; 2016 ел, 9 июль, 465 нче; 2016 ел, 2 сентябрь, 610 нчы; 2017 ел, 24 август, 598 нче; 2018 ел, 11 апрель, 447 нче, 2019 ел, 12 апрель, 280 нче; 2021 ел, 28 апрель, 288 нче; 2021 ел, 3 август, 676 нчы; 2021 ел, 1 декабрь, 1152 нче; 2022 ел, 28 февраль, 184 нче; 2022 ел, 13 август, 805 нче; 2022 ел, 26 август, 907 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясе чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Тикшерелгән бизнес» сайтын модернизацияләү – проектның яңа фирма стилен булдыру, «Тикшерелгән бизнес» сайтының функциональ элементлары дизайнын эшкәртү, «Тикшерелгән бизнес» сайтының навигация, фильтрлау һәм андагы мәгълүматны график чагылдыру функционалын киңәйтү буенча эшләр комплексы.»;

1.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле «в» пунктчасын өстәргә:

«в) «Тикшерелгән бизнес» сайтын модернизацияләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү.»;

1.5 пунктның икенче абзацында «1.3 пунктындагы «а» пунктчасының икенче – өченче абзацларында һәм «б» пунктчасының алтынчы абзацында» сүзләрен «1.3 пунктындагы «а» пунктчасының икенче – өченче абзацларында, «б» пунктчасының алтынчы абзацында, «в» пунктчасында» сүзләренә алмаштырырга;

1.6 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет система-сының бердәм порталындагы «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

1.7 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Бу Тәртипнең 1.3 пунктындагы «в» пунктчасында күрсәтелгән чараларны тормышка ашырганда финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) субсидия бирелә торган чыгымнарның юнәлешләре – түбәндәге чыгымнар:

«Тикшерелгән бизнес» сайтын модернизацияләү буенча эшләр башкару яки хезмәтләр күрсәтү максатларында төзелә торган шартнамәләр буенча түләүгә бәйле эшләр башкару яки хезмәтләр күрсәтү;

«Тикшерелгән бизнес» сайтын модернизацияләүдә кулланыла торган компьютер, сервер, телекоммуникация һәм башка җиһазларны тоту һәм эксплуатацияләү.»;

2.8 пунктның «б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия биргәндә:

бу Тәртипнең 1.3 пунктындагы «а» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән чараны тормышка ашырганда – бирелгән субсидиягә тигез күләмдә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирелгән микрозаемнар суммасы;

бу Тәртипнең 1.3 пунктындагы «а» пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән чараны тормышка ашырганда – бирелгән субсидиягә тигез күләмдә үзмәшгуль гражданнарга бирелгән микрозаемнар суммасы;

бу Тәртипнең 1.3 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән чараны тормышка ашырганда – кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына күрсәтелгән хезмәтләр саны – кимендә 16 286 берәмлек;

бу Тәртипнең 1.3 пунктындагы «б» пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән чараны тормышка ашырганда – экспортка ярдәм үзәге хезмәтләре күрсәтелгәне кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары саны – кимендә 50 берәмлек;

бу Тәртипнең 1.3 пунктындагы «б» пунктчасының дүртенче абзацында күрсәтелгән чараны тормышка ашырганда – хезмәтләр күрсәтелгән, бизнес алып барырга теләгән, яңа гына эшли башлаган һәм эшләгән уникаль гражданнар саны – кимендә 11 100 кеше;

бу Тәртипнең 1.3 пунктындагы «б» пунктчасының бишенче абзацында күрсәтелгән чараны тормышка ашырганда – ярдәм күрсәтелгән, шул исәптән уку программаларын үткән үзмәшгуль гражданнар саны – кимендә 10 кеше;

бу Тәртипнең 1.3 пунктындагы «б» пунктчасының алтынчы абзацында күрсәтелгән чараны тормышка ашырганда – чараларны тормышка ашыруга җәлеп ителгән затлар саны – кимендә 10 кеше һәм (яки) онлайн һәм офлайн массакүләм мәгълүмат чараларына, социаль медиага чыгу/ аларда язмалар бастырып чыгару саны – кимендә 1 518 берәмлек;

бу Тәртипнең 1.3 пунктындагы «в» пунктчасында күрсәтелгән чараны тормышка ашырганда:

«Тикшерелгән бизнес» сайтында дүрт төп модуле – мәгълүмат белән идарә итү, интеграция, җыелма мәгълүмат графиклары һәм файдалану хокукы булган мәгълүмат белән идарә итүнең модернизацияләнгән функционалы;

эшмәкәрләрнең 40 контроль төре буенча үзтикшерү узу өчен интерактив чекбитләр.

Бу пунктчада күрсәтелгән нәтиҗәләргә ирешү срогы – субсидия бирелгән елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча.

2022 елда субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә Килешүдә билгеләгән срокларда ирешү мөмкинлеге булмауга китерә торган шартлар барлыкка килгән очракта, Вәкаләтле орган, Фонд белән килештереп, субсидия күләмен үзгәртмичә, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү срокларын (әмма иң күбе 24 айга) озайту өлешендә Килешүгә үзгәрешләр кертү турында карар кабул итәргә хокуклы. Субсидия күләмен үзгәртмичә, субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү мөмкинлеге булмаган очракта, Вәкаләтле орган субсидия бирү нәтиҗәсенең күрсәткечен кимегү турында карар кабул итәргә хокуклы.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин